| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯШЕЛ ҮЗӘН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫ АЧАСЫР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 1 марты №8

Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» 2020 елның 17 февралендәге 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәтләр исемлеген актуальләштерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге башкарма комитеты **карар итә:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 17 февралендәге 3 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр исемлеген, 1 нче кушымтада түбәндәге эчтәлекле 6 пункт белән муниципаль хезмәтләр исемлеген өстәргә:

- муниципаль милектә булган җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында килешү төзү.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Олы Ачасыр авыл җирлеге мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек

хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы М.Г. Гатиятуллин